МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кремлевская ул., д. 9; Казань, 420111
Тел.: (843) 292-92-12; тел./факс: 292-93-51
E-mail: mon@tatar.ru http://www.mon.tatar.ru
ОКПО 00099837, ОГРН 1021602833196
ИНН/КПП 1654002248 / 165501001

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

Кремль урамы, 9 нчы йорт, Казан шәһәре, 420111,
Тел.: (843) 292-92-12; тел./факс: 292-93-51
E-mail: mon@tatar.ru http://www.mon.tatar.ru
ОКПО 00099837, ОГРН 1021602833196
ИНН/КПП 1654002248 / 165501001

Татарстан Республикасы
муниципаль районнары
башкарма комитетларының
мәгариф идарәләре һәм бүлекләре
җитәкчеләренә

Күренекле мәгърифәтче, галим
Ибраһим Хәлфин истәлегенә багышланган
IX республика фәнни-эзләнү укучылар конференциясен
үткәрү турында

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының 2013-2014 нче уку елына эш планы нигезендә укучыларда тикшеренү осталыгы, коммуникатив хәбәрдарлык формалаштыру, телебезгә, милли гореф-гадәтләребезгә, рухи байлыгыбызга мәхәббәт, үсеп килүче яшь буында мәгариф, мәдәният һәм икътисади үсештә гомерләрен татар халкына хезмәт итүгә багышлаган Хәлфиннәр нәселенең бай тарихи мирасын өйрәнүгә кызыксыну уяту, фәнни эзләнүләрдә иҗадилыкка омтылыш тәрбияләү максатыннан Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы 2014 нче елның 8 нче февралендә Казан шәһәре Башкарма Комитеты Мәгариф идарәсе белән берлектә Казан шәһәренең 14 нче гимназиясендә күренекле мәгърифәтче, галим Ибраһим Хәлфин истәлегенә багышланган IX республика фәнни-эзләнү укучылар конференциясе үткәрә.

Конференциядә катнашу өчен гариза, тезис һәм фәнни эш **G14.kzn@edu.tatar.ru, halfinc@yandex.ru** адресына 2014 нче елның 20 нче гыйнварына кадәр җибәрелә.

Хәбәрләшү өчен телефоннар: (843) 571-62-38, 571-62-48.

Нигезләмә татар һәм рус телләрендә теркәлә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
Татарстан Республикасы мәгариф
һәм фән министры Э.Н. Фәттахов

И.Ж. Гомәрова,292-27-74


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

**Күренекле мәгърифәтче, галим Ибраһим Хәлфин истәлегенә багышланган IX республика фәнни-эзләнү укучылар конференциясен үткәрү турында нигезләмә**

## 1.Гомуми мәгълүмат

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы тугызынчы ел рәттән Казан Идел буе Федераль университетының сәнгать һәм филология институты, Казан шәһәре Башкарма Комитеты Мәгариф идарәсе, Казан шәһәренең мәгълүмати-методик үзәге һәм муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе «Гимназия №14» (алга таба - «Гимназия») белән берлектә күренекле мәгърифәтче, галим Ибраһим Хәлфин истәлегенә багышланган республика фәнни-эзләнү укучылар конференциясен (алга таба- Конференция) үткәрә. Конференциядә татар халкының мәгарифе, мәдәнияты һәм икътисади үсешенә зур өлеш керткән Хәлфиннәр нәселенең тормышы һәм иҗади эшчәнлеге төрле юнәлешләрдә өйрәнелә һәм тикшерелә.

Әлеге нигезләмә Конференция үткәрүнең максатын, бурычларын билгели; оештыру, үткәрү, йомгаклау, җиңүчеләрне бүләкләү тәртибе белән таныштыра.

## 2.Конференциянең максаты һәм бурычлары

2.1. Конференциянең максаты –төрле фәннәр буенча эзләнү эшчәнлеге аша укучыларның иҗади фикер йөртүләрен, интеллектуаль сәләтләрен активлаштыру.

2.2. Төп бурычлары:

- хәзерге заман укучысының гомуми һәм коммуникатив культура дәрәҗәсен, социаль активлыгын үстерү һәм җәмгыятьтә үз урынын табарга өйрәтү;
- талантлы һәм сәләтле балаларны барлау, алга таба аларның сәләтләрен үстерүгә мөмкинлекләр тудыру, ярдәм итү;
- укучыларның иң яхшы казанышларын, белем бирү оешмаларының фәнни эшчәнлек белән шөгыльләнү тәҗрибәсен өйрәнү, тәкъдим итү һәм пропагандалау;
- тикшеренү эше алып баручы коллективлар белән иҗади бәйләнешләр формалаштыру, үзара аралашу оештыру;
- укучыларда милләтнең мәгариф, мәдәният һәм икътисади үсешендә гомерләрен үз халкына хезмәт итүгә багышлаган Хәлфиннәр нәселенең бай тарихи мирасын өйрәнүгә кызыксыну уяту, яшь буынны аларның тормыш юлы һәм иҗаты үрнәгендә тәрбияләү;
- милли үзаң, үз милләтеңнең тарихына, мәдәниятына, гореф-гадәтләренә хөрмәт һәм мәхәббәт тәрбияләү;
- заман таләпләренә ия булган сыйфатлы белем бирүгә ирешү;

- мәктәп һәм югары уку йортлары системасы аша укучыларда иртә һөнәри юнәлеш булдыру.

3. **Конференция кысаларында түбәндәге секцияләр эшләячәк:**

- Татар филологиясе
- Рус филологиясе
- Тел белеме һәм сөйләм культурасы (рус, татар һәм чит телләр)
- Ватан тарихы һәм туган якны өйрәнү
- Математика, информатика, физика
- Биология, химия, экология
- Дөнья мәдәнияте һәм диннәр тарихы
- Психология, «Кеше тормышында спортның роле» (спорт ярышларының тарихы; әдәбиятта һәм рәсем сәнгатендә спорт темасы; уеннар презентациясе)
- Дөнья цивилизациясе контекстында милли сәнгать, әдәбият һәм мәгариф*.

* Ел саен әдәбият, сәнгать һәм мәгариф өлкәсендәге тирән эз калдырган бер татар зыялысының тормыш юлы һәм иҗатын тирәнтен өйрәнгән “Дөнья цивилизациясе контекстында милли сәнгать” секциясе 2014 нче елда күренекле композитор Рөстәм Яхинның тормыш юлы һәм иҗатына багышлана һәм түбәндәге темаларны үзенә алачак:

1. Рөстәм Яхинның тормыш юлы һәм иҗаты
2. Рөстәм Яхин замандашлары истәлекләрендә
3. Татарстанның милли символлары
4. Гимннарда Рәсәй тарихы

Секциянең төп эш юнәлешләре:

1. Рөстәм Яхин иҗатына багышланган дәрес һәм дәрестән тыш чараларның эшкәртмәләрен яклау (укытучылар өчен).
2. Композитор иҗаты турында иң шәп компьютер презентациясен яклау (укучылар өчен).
3. Рөстәм Яхин иҗатын иң яхшы белүчеләр бәйгесе.

«Мәктәптә Рөстәм Яхин мирасын өйрәнү» дигән темага түгәрәк өстәл (укытучылар өчен).

4. **Бәяләү критерийлары**

Казан Федераль университетының сәнгать һәм филология институты мөгаллимнәре, Казан шәһәренең мәгълүмати-методик үзәге методистлары, Казан шәһәре белем бирү учреждениеләренең югары квалификация категорияле укытучыларыннан торган экспертлар комиссиясе укучыларның фәнни эшләренә, чыгышларына түбәндәге критерийлардан чыгып бәя бирә:

- тикшеренү эшендә билгеле булган нәтиҗәләр һәм фәнни фактларны куллану;
- кулланылган әдәбиятның сыйфаты;
- чыгыш ясаучының сөйләме, аралашу культурасы;
- максатны аңлау;
- проблеманың заманча халәтен белү (хәбәрдар булу);
- тикшеренү эшендә Хәлфиннәр нәселенең тормыш юлы һәм иҗади эшчәнлеге чагылышы;
- авторның мөстәкыйльлек дәрәҗәсе;
- сайланган теманың актуаль булуы;
- проблеманы чишүнең тирәнлеге, тулылыгы, үзенчәлекле ысулларны кулланган булуы;
- фәнни эштә логик эзлеклелек саклану;
- чыгышның композицион бөтенлеге, теманы ача һәм дәлилли белү дәрәҗәсе;
- чыгышны күрсәтмә материал белән баету;
- коммуникабельлек компетенциясе (җиңел аралаша белү осталыгы).

Экспертлар һәр юнәлеш буенча бәя бирү критерийларын конкретлаштыру хокукына ия.

Чыгыш ясау өчен укучыга 5-7 минут вакыт бирелә. Шул вакыт эчендә укучы төп фикерләрне кыска һәм төгәл итеп җиткерә белергә тиеш.

## 5. Бәйгене оештыручылар

- Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы
- Казан шәһәре Башкарма Комитеты Мәгариф идарәсе
- Казан Федераль университетының сәнгать һәм филология институты
- Казан шәһәренең мәгълүмати-методик үзәге
- Муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе «Гимназия №14»

## 6. Бәйгене үткәрү һәм катнашу тәртибе

6.1. 2013 нче елның 20 нче декабреннән 20 нче гыйнварына кадәр « Гимназия № 14» конференциядә катнашу өчен гаризалар, тезислар, фәнни эшләр кабул итә.

6.2. Конференциядә укучылар фәнни-эзләнү эшләре белән катнаша. Эшләр мөстәкыйль эшләнгән, мәгълүматлар анализланган һәм аларда авторның үз карашы, фикере чагылырга тиеш.

6.3. Республиканың шәһәр һәм район мәктәп, гимназия, лицейларында белем алучы укучылар (Казан шәһәреннән кала) 2014 нче елның 20 нче гыйнварына кадәр гариза, тезис һәм фәнни эшләрен **G14.kzn@edu.tatar.ru яки halfinc@yandex.ru** адресларына - электрон әрҗәләрнең берсенә җибәрә ала.

6.4 2014 нче елның 20 нче гыйнварыннан 28 нче гыйнварына кадәр Конференция читтән торып үтә – килгән эшләр тикшерелә. Килгән эшләрне, оештыру комитеты составына кергән экспертлар тикшергәннән соң, икенче

турда катнашучылар исемлеге 1 нче февральдә гимназиянең официаль сайтына куела.

6.5. Икенче турга узган укучылар 8 нче февраль көнне сәгать 10 га Казан шәһәренең 14 нче гимназиясенә Конференциясенең финалына чакырыла. Алар секцияләрдә чыгышлар ясый. Фәнни-эзләнү эшләренең кәгазь варианты чыгыш ясар алдыннан экспертлар комиссиясенә тапшырыла. (Адрес: Казан шәһәре, Авиатөзелеш районы, Луначарский урамы, 9 нчы йорт. Хәбәрләшү өчен телефон: (843) 571-62-38, 571-62-48).

6.6. Экспертлар комиссиясе карары буенча иң яхшы тикшеренү эшләренең тезислары җыентыгын Конференциянең икенче турына кадәр бастырып чыгару планлаштырыла.

## 7. Катнашучылар

Конференциядә катнашу өчен мәктәп, гимназия, лицейларның 4 – 11 нче сыйныф укучылары чакырыла.

Конференциядә аерым укучылар эше, шулай ук 2-3 кешедән торган күмәк эшләр дә катнаша ала.

## 8. Фәнни-эзләнү эшенең эчтәлегенә һәм калыбына таләпләр

8.1. Фәнни-эзләнү эшенең структурасы

Фәнни эш кабул ителгән стандарт кысаларында билгеле бер структурага нигезләнеп үтәлә. Титул бите, эчтәлек, кереш, төп өлеш, йомгак, кулланылган әдәбият исемлеге, кушымта кебек өлешләрдән тора. Фәнни эшнең тексты компьютерда җыелган булырга тиеш. Күләме 15-20 бит. Шрифт Times New Roman – 14. Полялар: сулдан – 30 мм, уңнан – 15 мм, астан һәм өстән – 20 мм. Юл араларында 1,5 интервал кала. Кызыл юл 1см калдырып башлана.

Фәнни эш үтәкүренмәле тышлы папкага урнаштырылып, 1 данәдә тапшырыла.

8.2. Тезисларны тәкъдим итү тәртибе

1. Тезислар Word редакторында А4 форматында 1 интервал белән җыелырга тиеш. Шрифт Times New Roman – 14; өстән, астан, уңнан, сулдан полялар – 2 см. Полялар рамка эченә алынмый.

2. Тезисларның калыбы түбәндәгечә булырга тиеш:

- фәнни-эзләнү эшенең төп фикерләре кыскача чагылыш таба;
- кат-кат тикшерелгән, төзәтүләрсез була;
- компьютерда җыела, А4 форматындагы кәгазьнең бер ягына гына сыйфатлы итеп принтерда чыгарылган була;
- исеме уртага 14 нче шрифтны калынайтып язылa, ахырда нокта куелмый;
- авторның исеме, фамилиясе тулаем күрсәтелә, мәктәбе, сыйныфы, фәнни җитәкчесенең фамилиясе 14 нче шрифт белән битнең уң як өлешенә языла;
- яңа юлдан башланучы фразалар кызыл юлдан 1 см калдырылып башлана.

3. Тезис исеме, авторы, фәнни җитәкчесе турындагы мәгълүматлар белән тезис тексты арасындагы ара 1 интервалны тәшкил итә.

4. Тезисларның күләме – 1 бит.

5. Тезислар электрон һәм кәгазь вариантларында тапшырыла.

**9.Нәтиҗә чыгару һәм җиңүчеләрне бүләкләү**

Укучыларның фәнни эшләренә, чыгышларына экспертлар комиссиясе (жюри) бәяләү критерийларыннан чыгып бәя бирә. Чыгышлар тыңланып беткәннән соң һәр секциядәге экспертлар комиссиясе нәтиҗә чыгара, җиңүчеләрне билгели. Карар беркетмәгә теркәлә, үзгәрешсез кабул ителә.

2 нче турда катнашкан барлык укучыларга да Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Катнашучы шаһәдәтнамәсе» тапшырыла.

Җиңүчеләр һәм призлы урыннарга ия булучылар Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының дипломнары белән бүләкләнә. Лауреат (IV-V урыннар) исемен алучыларга Казан Федераль университеты сәнгать һәм филология институтының дипломнары тапшырыла. Җиңүчеләрне әзерләгән укытучылар Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Рәхмәт хатлары» белән бүләкләнә. Конференция нәтиҗәләре буенча Мәгариф һәм фән министрлыгының боерыгы әзерләнә.

Кушымта№ 1

**Күренекле мәгърифәтче, галим Ибраһим Хәлфин истәлегенә багышланган IX Республика фәнни-эзләнү укучылар конференциясен оештыручыларга гариза**

Укучыны тәкъдим итүче белем бирү оешмасы (Устав буенча)_______________________________________________________________
Белем бирү оешмасының электрон әрҗәсе ___________________________
Телефон_________________________________________________________________
Белем бирү оешмасы җитәкчесе (фамилия, исем, әтисенең исеме)_____________________________________________________________

**Катнашучы турында мәгълүмат**

Фамилия, исем, әтисенең исеме______________________________________________
Уку урыны, сыйныфы_______________________________________________________
Туган көне________________________________________________________________
Өй адресы ________________________________________________________________
Телефоны_________________________________________________________________
Электрон әрҗәсе___________________________________________________________

Катнашырга теләк белдергән юнәлеш_________________________________________

**Фәнни эшнең җитәкчесе турында мәгълүмат**

Фамилия, исем, әтисенең исеме______________________________________________

Эш урыны, вазыйфасы______________________________________________________
Телефоны_________________________________________________________________
Электрон әрҗәсе___________________________________________________________
Кирәкле техник чаралар_____________________________________________________

# ПОЛОЖЕНИЕ

## о IX Республиканской научно-исследовательской конференции школьников, посвященной памяти татарского ученого-просветителя Ибрагима Хальфина

**I. Общие положения**

Республиканская научно-исследовательская конференция школьников имени Ибрагима Хальфина (далее по тексту - Конференция) проводится ежегодно Министерством образования и науки Республики Татарстан (далее – МО и Н РТ), Федеральным государственным автономным образовательным учреждением высшего профессионального образования «Казанский (Приволжский) Федеральный университет Институт филологии и искусств (далее по тексту - К(П)ФУ ИФИ), муниципальным учреждением «Управление образования Исполнительного комитета муниципального образования города Казани» (далее – УО), муниципальным методическим учреждением «Городской методический центр» (далее по тексту - ГМЦ), муниципальным бюджетным образовательным учреждением «Гимназия № 14» Авиастроительного района г. Казани (далее по тексту - Гимназия). На Конференции изучается и исследуется в разных направлениях жизнь и научная деятельность династии Хальфиных, внесших большой вклад в развитие образования, культуры и экономики татарского народа.

Положение о IX Республиканской научно-исследовательской конференции школьников, посвященной памяти видного татарского ученого-просветителя Ибрагима Хальфина, знакомит с целями, задачами, порядком организации, проведением, подведением итогов и награждением победителей конференции.

**2.Цели и задачи Конференции:**

Целью конференции является создание условий, стимулирующих развитие интеллектуального творчества учащихся посредством вовлечения их в исследовательскую деятельность в области гуманитарных и естественно-математических наук.

**Задачи Конференции:**

- повышение уровня общей и коммуникативной культуры современного школьника, социальной активности и самореализации;
- выявление одарённых и талантливых школьников для последующей поддержки и развития их способностей;
- демонстрация и пропаганда лучших достижений учащихся, опыта работы учебных заведений по организации учебной и научно-исследовательской деятельности;
- формирование творческих связей с исследовательскими коллективами, организация взаимного общения;


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

- изучение и популяризация богатого исторического наследия династии Хальфиных, оставивших след в развитии национального образования, культуры и экономического развития; воспитание молодого поколения на примере их жизненного пути и творчества;
- воспитание школьников на примерах жизни и творчества видных деятелей культуры, просвещения, искусства и науки;
- формирование национального самосознания, уважения и любви к истории, культуре, традициям родного народа;
- достижение современного качества образования;
- обеспечение ранней профессиональной ориентации учащихся через систему «школа-вуз».

**3. Секции, работающие в рамках Конференции**

Конференция предусматривает работу секций, включающих предметы следующих образовательных областей:

1. Проблемы русской филологии (литературоведение).
2. Проблемы татарской филологии (литературоведение).
3. Языкознание и культура речи (русский, татарский и английский языки).
4. История Отечества и краеведение.
5. Математика. Физика. Информатика.
6. Биология, химия, экология.
7. Мировая художественная культура и история религии.
8. Психология, «Спорт в жизни человека» (история спортивных состязаний, игр; тема спорта в живописи и литературе, презентация игротеки…).
9. Национальная культура в контексте мировой цивилизации (посвященная творчеству одного из видных деятелей татарской культуры, просвещения, литературы и искусства). Работа секции в 2014 году будет посвящена творчеству композитора Рустема Яхина («Романтик в музыке и душе») и будет охватывать следующие темы:

1. Рустем Яхин: Судьба и грани творчества.
2. Рустем Яхин в воспоминаниях современников.
3. Национальные символы Татарстана.
4. История России в гимнах.

Основные направления работы данной секции:

Стендовая защита урока, внеклассных мероприятий, посвященных творчеству Рустема Яхина (для учителей).

Конкурс на лучшую компьютерную презентацию о творчестве композитора (для учащихся).

Конкурс знатоков творчества Рустема Яхина.

Круглый стол для учителей «Изучение творческого наследия Рустема Яхина в школе: состояние и перспективы».

**4. Критерии оценки работ**

Экспертные комиссии предметных секций формируются из ученых, преподавателей Института филологии и искусств Казанского (Приволжского) федерального университета, специалистов учреждений, осуществляющих научно-методическое обеспечение, учителя высшей квалификационной категории и оценивают работы по следующим критериям:

- использование в исследовательской работе известных результатов и научных фактов;
- владение современным состоянием проблемы;
- умение использовать источники, литературу по данной проблеме (полнота цитируемой литературы, ссылки на исследования ученых);
- лингвистическая компетенция (владение языковыми нормами);
- понимание цели;
- логика изложения, убедительность аргументации, чёткие выводы;
- отображение в исследовательской работе жизни и научной деятельности династии Хальфиных;
- самостоятельность суждений;
- оригинальность, творческий подход к выполнению представленной работы;
- коммуникативная компетенция.

Регламент выступления участников Конференции предусматривает публичную защиту научно- исследовательской работы продолжительностью 5-7 мин.

**5. Организаторы конференции**

Для организационно-методического обеспечения Конференции создается оргкомитет.

Состав оргкомитета формируется из представителей:

- Министерства образования и науки Республики Татарстан,

- муниципального учреждения «Управление образования Исполнительного комитета муниципального образования города Казани»,

- Института филологии и искусств ФГАОУ ВПО «Казанский (Приволжский) федеральный университет»,

- муниципального методического учреждения «Городской методический центр»,

- руководства муниципального бюджетного образовательного учреждения «Гимназия №14» Авиастроительного района г. Казани, на базе которого проводится Конференция.

## 6. Порядок организации и проведения

6.1. В период с 20 декабря 2013 года по 20 января 2014 года в МБОУ «Гимназия №14» Авиастроительного района г. Казани для участия в Конференции представляются заявления, тезисы и научно-исследовательские работы.

6.2. Участники представляют в адрес оргкомитета Конференции заявку на участие.

Исследовательские работы предполагают осведомлённость о современном состоянии области исследования, владение методикой эксперимента, наличие данных о проведённых собственных исследованиях, их анализ, обобщение и выводы.

6.3. Учащиеся городских и районных школ, гимназий, лицеев (кроме Казани) до 20 января 2014 года могут направить заявления, тезисы и научно-исследовательские работы на один из электронных адресов: G14.kzn@edu.tatar.ru, e-mail: halfinc@yandex.ru.

6.4. С 22 по 30 января 2014 года проводится заочный тур Конференции.

В случае положительного результата рецензирования научно-исследовательской работы (доклада) в адрес участника и его научного руководителя оргкомитет направляет вызов для публичного выступления на Конференции. Со списком учащихся, прошедших во 2 тур Конференции можно до 1 февраля 2014 года ознакомиться на официальном сайте гимназии.

6.5. Учащиеся, прошедшие во 2 тур конференции, 8 февраля 2014г приглашаются на финал научно-исследовательской конференции школьников, посвященной памяти видного татарского ученого-просветителя Ибрагима Хальфина.

Место проведения Конференции**-** МБОУ «Гимназия №14» Авиастроительного района г.Казани.

Адрес: 420047 г. Казань, ул.Луначарского, д. 9,

Телефон:(843) 571-62-38, 571-62-48, факс: 571-62-38.

Сайт в Интернете: G14.kzn@edu.tatar.ru, e-mail: halfinc@yandex.ru

6.6. Оргкомитет Конференции имеет право по решению экспертных комиссий опубликовать тезисы лучших научно-исследовательских работ учащихся (объемом не более 1 страницы) до 2 тура Конференции.

## 7. Участники Конференции

В Конференции принимают участие школьники (4-11 классы) средних общеобразовательных учебных заведений Республики Татарстан (школы, лицеи, гимназии).

В конференции могут участвовать как по отдельности, так и группами, состоящими из 2-3 учащихся.

## 8. Основные правила к содержанию и оформлению научно-исследовательской работы

8.1.Структура исследовательской работы

Работа должна быть построена не произвольно, а по определенной структуре, которая является общепринятой для научных трудов.

Основными элементами этой структуры являются: титульный лист, оглавление, введение, основная часть, заключение, список использованной литературы, приложения.

Текст исследовательской работы должен быть напечатан на компьютере шрифтом 14 пунктов на одной стороне стандартного листа белой бумаги форматом А4 через 1,5 межстрочный интервал. Формулы в текст можно вписать вручную (черными чернилами). Исследовательская работа должна быть помещена в папку – скоросшиватель с прозрачным верхним листом.

При оформлении работы рекомендуется оставлять поля вокруг текста следующих размеров: левое-30 мм, правое – 15мм, верхнее и нижнее – 20 мм. Контуры полей не наносятся.

8.2.Общие требования к оформлению тезисов

1.Текст тезисов должен быть напечатан на компьютере и распечатан в «качественном» режиме на одной стороне белой бумаги формата А4. Оформление производится в текстовом редакторе Microsoft Word через межстрочный интервал -1, шрифтом Times New Roman 14 пунктов с отступом от края сверху и снизу, слева 2 см и справа 2 см и форматируется по ширине всего листа. Контуры полей не наносятся.

2. Тезисы должны быть оформлены следующим образом:

- кратко должны быть представлены основные мысли научно-исследовательской работы;

- должны быть тщательно отредактированы и не содержать ошибок;

- напечатаны на компьютере, и распечатаны только на 1 стороне бумаги форматом А4;

- заголовок текста тезисов печатается жирным прописным шрифтом 12 пунктов и форматируется по центру. Точка в конце заголовка, располагаемого посредине строки, не ставится;

- фамилия и имя автора (**указывать полностью**), класс, школа; фамилия, имя, отчество **(полностью**) научного руководителя печатается по образцу шрифтом 14 пунктов и форматируется справа листа;

- фразы, начинающиеся с новой строки, печатаются с абзацным отступом от начала строки, равным 1 см (красная строка);

3. Расстояние между заголовком тезиса, фамилиями авторов, школой и классом, научным руководителем и последующим текстом должно быть равно одному интервалу.

4. Объем текста тезисов – 1 страница.

5. Тезис сдается в электронном и бумажном виде.

**9. Подведение итогов и награждение победителей**

Публичное выступление участника на Конференции оценивается в соответствии с разработанными критериями.

По окончании заслушивания публичных выступлений участников Конференции проводятся заседания экспертных комиссий по каждой предметной секции отдельно, на которых подводятся итоги и выносятся решения о победителях.

Решения экспертных комиссий протоколируются, являются окончательными. Участники 2 тура Конференции получают сертификат участника Конференции.

Победители и призеры (I, II и III места) Конференции награждаются Дипломами МОиН РТ. Лауреаты (IV и V места при их наличии) награждаются грамотами ИФИ К (П)ФУ.

Научные руководители победителей и призеров Конференции награждаются Благодарственными письмами МОиН РТ.

По итогам проведения Конференции издается приказ по Министерству образования и науки Республики Татарстан.

Приложение №1

**Образец заявки**

| | |
|---|---|
| Название работы | |
| Секция, для участия в которой направлена работа ученика | |
| Фамилия, имя автора (полностью) | |
| Класс | |
| Адрес и телефон участника | |
| Фамилия, имя, отчество руководителя (полностью), должность, квалификация, ученая степень | |
| Организация, представляющая работу | |
| Адрес и телефон организации | |
| Необходимые технические средства для демонстрации по ходу выступления и презентации дополнительного материала (компьютер, диапроектор, кодоскоп, экран и т.д. **указать в правой стороне заявки**) | |

Подпись руководителя учреждения,
направляющего участника Конференции

«_________»________________________________20___г. ___________________

М.П.


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Лист согласования к документу № 16362/13 от 21.11.2013
Инициатор согласования: Гумарова И.З. Ведущий консультант отдела национального образования и межрегионального сотрудничества
Согласование инициировано: 21.11.2013 11:55

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Шарипова А.С. | - | Согласовано 21.11.2013 17:33 | - |
| 2 | Мустафин Д.М. | - | Согласовано 21.11.2013 19:58 | - |
| 3 | Фаттахов Э.Н. | - | Подписано 22.11.2013 07:59 | - |